Республика Татарстан
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
**СОВЕТ**
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«КАРКАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»

ул.Советская, д.93, с.Каркали.
Лениногорский район, 423272
Тел./факс: (85595) 3-67-01
E-mail: Kark.Len@tatar.ru

Татарстан Республикасы
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

«КЕРКӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 93 йорт, Керкәле авылы, Лениногорск районы, 423272
Тел./факс: (85595) 3-67-01
E-mail: Kark.Len@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 14 мартыннан № 9

### Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 04 декабрендәге 25а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2013 елның 04 декабрендәге 25а номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

12 статьяның 5 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«әгәр мондый килешү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 маддәсендә каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтен килештерү.»;

19 статьяның 2 өлешендә «бер ай һәм өч айдан артык» сүзләрен «ундүрт көн һәм утыз көннән артык» сүзләренә алмаштырырга.

2.Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле авылы, Совет урамы, 93 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырырга.https://pravo.tatarstan.ru/

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Л.И.Бигманов